странными студентами свидетельствует о необходимости использования в качестве учебно-методической литературы по изучаемому предмету двуязычных словарей различного типа: русско-национальных, национально-русских, с толкованиями или без толкования терминов. Словари предоставляют визуальную опору, оказывают помощь при проработке лекций, способствуют расширению профессионального тезауруса студентов, повышают мотивации к изучению иностранного языка, оказывают помощь в усвоении научно-технической литературы, развивают точную, лаконичную, понятную в изложении устную и письменную речь.

Перспективным направлением является использование электронного учебно-методического комплекса дисциплины на двуязычной основе в технологиях обучения иностранных студентов в технических и технологических русскоязычных вузах.

Таким образом, нами представлены ключевые моменты преподавательской деятельности и учебной деятельности студентов первого курса при их учебно-дидактической адаптации в процессе изучения химических дисциплин на двуязычной основе.

**Насибуллова Г.Р., Шәрифуллина Р.Р.**

## ЧИТ ТЕЛГӘ ӨЙРӘТҮ АЛЫМЫ БУЛАРАК ТӘРҖЕМӘ

*Казан (Идел буе) федераль университеты, Казан шәһәре*
*Ш.З. Зиннуров исемендәге Саба муниципаль районы*
*Сатыш гомуми белем бирү урта мәктәбе, Сатыш авылы*

Чит телгә өйрәтүдә тәрҗемә алымын куллану уку-укыту системасында һәрвакыт актуаль һәм методиканың үсеш дәверендә аңа карата методистларның фикерләре төрлечә. XIX нчы гасыр уртасында чит телгә өйрәтүдә кулланыла торган күнегүләренең күпчелеге диярлек тәрҗемәләргә нигезләнгән. Ләкин гасыр ахырында альтернатив алымнар эзләү башлана. Тәрҗемә хәтта дәресләкләргә бөтенләй кертелми башлый. Яңа концепцияләр үсеше, берничә фәнне бәйләп өйрәнү чит тел укыту методикасына да тәэсир итә. Шуңа күрә XX гасыр дәвамында капма-каршы юнәлешләр барлыкка килә: кайбер методистлар тәрҗемәне дәресләкләрдән тулысынча алып ташларга омтылса, икенчеләре аны чит тел укытуда төп методларның берсе дип саный. Мәсәлән, Е.И. Пассов бер генә тел яклы. Аның фикеренчә, тәрҗемә – ул аңлы рәвештә чит телне туган тел белән чагыштыру, тәрҗемә процессында тәрҗемә итәргә өйрәтергә түгел, ә шул аңлы рәвештә чагыштыруга ирешергә кирәк. А.П. Старков тәрҗемә итүне куллануны чикләү яклы, аны бары тик башка алымнар эффектив булмаган очракта гына кулланырга мөмкин дип саный. С.Ф. Шатилов тәрҗемә итүне системалаштыру чарасы буларак кына кулланырга тәкъдим итә [1].

Бүгенге көндә чит телгә өйрәтү методикасының төп алымы – коммуникатив күнекмәләргә өйрәтү. Ләкин укыту алымы буларак тәрҗемә тулысынча кире кагылмаса да, бу сорау ачык булып кала бирә. Шуңа да кара-

мастан тәрҗемә чит телгә өйрәтү системасында мөһим роль уйный. Туган телгә таяну, чит телне туган тел белән чагыштырып өйрәтү өйрәнелә торган телне җиңелрәк үзләштерүгә ярдәм итә.

Тәрҗемә бик мөһим социаль функция башкара. Ул төрле халыкларның телара аралашуына ярдәм итә. Әдәби әсәр тәрҗемәләре төрле халыкларның мәдәнияте белән танышуга күпер булып тора. Әдәби әсәр тәрҗемәләре укучыларда аеруча зур кызыксыну уята. Без укыту процессында чит телдән туган телгә, шулай ук туган телдән чит телгә әдәби әсәр тәрҗемәләре кулланабыз. Татар әдәбияты инглиз теленә аз тәрҗемә ителгәнлектән, укучылар бу өлкәдә үзләрен тәрҗемәче буларак сынап карарга яраталар.

“Тәрҗемә итү – димәк бер телдә бирелгәнне башка телдә дөрес һәм тулы чагылдыру” [2, 95] Чит телгә өйрәтү методикасында тәрҗемә “өйрәнү тәрҗемәсе” буларак кулланыла. Өйрәнү тәрҗемәсе – уку процессында чит телгә өйрәнүдә кулланылучы бер алым. Уку тәрҗемәсе чит телдә бирелгән текстны аңлауга нигезләнгән тәрҗемә. Бу алым чит телне өйрәнүгә, тәрҗемә методларын һәм техникасын үзләштерүгә, чит телдә сүзлек запасын киңәйтүгә ярдәм итә.

Чит телгә өйрәткәндә өйрәнү тәрҗемәсе берничә мәсьәләне хәл итәргә ярдәм итә:

- чит тел грамматикасы, лексикасы, синтаксис һәм стилистика өлкәсендәге белемнәрне ныгыту һәм системалаштыру;
- укучыларның тел компетенцияләрен киңәйтү;
- тәрҗемә эшчәнлегенең төп күнекмәләрен формалаштыру.

Ләкин шунысын искәртеп үтәргә кирәк: тәрҗемә ярдәмче чара буларак кына кулланыла, тәрҗемә эшчәнлегенең үсеше чит телгә өйрәтүгә нигезләнә.

Укучылар чит телне өйрәнгәндә, аеруча башлангыч этапларда, махсус яки эчке сиземләү аша лексик берәмлекләрне, грамматик конструкцияләрне һ.б. туган тел белән чагыштыралар. Бу аларга чит телдәге сөйләмне яки текстны аңларга ярдәм итә. Әйтергә кирәк, чит телдәге текстны (сөйләмне) тәрҗемәдән башка аңлау һәм кабул итү мөмкин түгел.

Шулай ук тәрҗемәсез аңлау дигән төшенчә дә бар. Бу аудио һәм визуаль аңлау. Тәрҗемәсез аңлау – чит телне өйрәнүнең соңгы этабы, бу алымга чит телне тулысынча диярлек өйрәнгәндә генә ирешеп була.Тәрҗемәсез аңлау алымын чит телне камил белүчеләрдә генә күзәтергә мөмкин. Мәктәптә чит тел өйрәткәндә әлеге алымны берничә сәбәп аркасында куллану мөмкин түгел: уку планында бирелгән вакытның аз булуы, укучыларның база әзерлегенең көчле булмавы, практика булмау һ.б. Тәрҗемәсез аңлауга телне киңрәк өйрәнү, укучыларның үз өстендә эшләү нәтиҗәсендә ирешергә мөмкин.

Югарыда әйтелгәннәрдән чыгып, без шундый нәтиҗәгә килдек: тәрҗемә процессын телара тәңгәллекләр табуның механик акты дип кенә аңларга мөмкин түгел. Нәкъ менә укучылар аерым сүзләрнең мәгънәсен белдерүгә омтылу аркасында тәрҗемә процессында хаталар килеп чыга. Төрле телләрнең аерым сүзләре яки конструкцияләре арасында тулысынча эквивалентлык табу да мөмкин түгел. Семантик һәм функциональ яктан ике тел-

нең билгеләре туры килми. Сөйләм әсәрен тулысынча аңламыйча сүзен сүзгә тәрҗемә итү мәгънәне бозуга китерә. Шулай ук бертуктаусыз сүзлеккә мөрәҗәгать итү чит телдәге текстны кабул итүне катлауландыра: уку темпын әкренәйтә, логик фикерләүне боза, игътибарны укылганнан читкә юнәлтә.

Тәрҗемәнең дөрес вариантын сайлауда төп рольне контекст, предметны дөрес аңлау уйный. Тәрҗемә – лингвистик һәм экстарлингвистик үзенчәлекләрнең үрелеше. Шул сәбәпле телгә өйрәткәндә укытучы текстны уйлап аңлауга өйрәтергә, даими телара параллельләр китерергә, башка тел системасының үзенчәлекләрен ассызыклап күрсәтергә бурычлы.

Тәрҗемә укыту алымы буларак аңлы рәвештә чагыштыруның нигезен тәшкил итә һәм чит тел өйрәнгәндә туган телгә мөрәҗәгать итүнең күләмен аклый. Тәрҗемә процедурасы алга таба булачак сөйләм эшчәнлегенә бәйле күнекмәләр һәм осталыклар өчен нигез булып тора, аеруча уку өчен. Өйрәнү чарасы буларак тәрҗемә чит телнең лингвистик үзенчәлекләрен туган телнең билгеле үзенчәлекләре белән чагыштырып ачыклау өчен мөмкинлек бирә. Текстны тәрҗемә итү өйрәнелә торган телләр илләренең тарихы, региональ үзенчәлекләре белән киңрәк танышырга ярдәм итә.

Шулай итеп, чит телдәге текстны тәрҗемә итү укучыларны уку төрләрен үзләштерүгә әзерләүдә зур роль уйный дип әйтә алабыз. Тәрҗемә белән даими шөгыльләнү мәгълүматны төрле яктан аңлау һәм кабул итү өчен күнекмәләр һәм осталыклар булдыруга хезмәт итә. Өйрәнү чарасы буларак тәрҗемә текстта очрый торган грамматик, лексик һәм стилистик кыенлыкларны чишәргә ярдәм итә. Тәрҗемә сөйләм эшчәнлекләренең башка төрләреннән үзенең тыңлап аңлау, сөйләү, уку һәм язуны берләштерүе белән генә түгел, ә икетеллелек шартларында башкарылуы белән дә аерыла һәм мөһим чара булып тора. Шулай да, чит телгә өйрәткәндә, тәрҗемәгә өйрәтү максат булып түгел, ә сөйләм эшчәнлегенең төрле төрләренә (тыңлап аңлау, уку, язу, сөйләү) өйрәтү чарасы буларак кына кулланылырга тиеш.

*Әдәбият*

1. Камышева Л.М. Коммуникативная направленность и перевод: антагонизм или совместимость? URL:www.t21.rgups.ru/doc2008/2/15.doc.

2. Федоров А.В. Основы общей теории перевода. Лингвистические проблемы. - М.: Высшая школа, 1983. - 303 с.

**Нургалиева З.К.**

## ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ТЕЗЕМНӘРНЕ ӨЙРӘТҮ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

*МАГББУ «Советлар Союзы герое С.Ә. Әхтямов исемендәге 121 нче лицей», Казан шәһәре*

XX гасыр башыннан татар теле грамматикасы бердәм терминология белән ныклап эшләү юлына кергән. Ул вакыттан бүгенге көнгә кадәр ул зур үзгәрешләр кичергән, камилләшкән. Тел белемендә шулай итеп яңа кү-